Исполнительный комитет
Урсаевского сельского поселения
Заинского муниципального
района
Республика Татарстан

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Урсай авыл җирлегенең
башкарма комитеты

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№7**

**КАРАР**
**22. 05. 2020 ел.**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге җирле үзидарә органына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә, Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге җирле үзидарә органына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибен расларга (кушымта).
2. Әлеге карарны Урсай авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Урсай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе** **Н.А. Гатина**

Зәй муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге
башкарма комитетының
22 мае 2020 елның
7 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге җирле үзидарә органына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясын, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге җирле үзидарә органына (алга таба - җирле үзидарә органына) гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Җирле үзидарә органнарына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау гражданнар мөрәҗәгатьләре керүгә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатларында гамәлгә ашырыла.

3. Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркатип) тарафыннан гамәлгә ашырыла (алга таба -вазыйфаи зат).

4. Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау ешлыгы – елга бер мәртәбә, ел төгәлләнгәннән соң.

5. Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тиешле вакыт аралыгында гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне, шул исәптән язмача рәвештә, электрон хәбәр формасында, шулай ук Интернет-кабул итү аша кергән, гражданнарны шәхси кабул итү вакытында алынган һәм телефон аша мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып башкарыла.

6. Вазыйфаи зат гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерүне һәм анализлауны гамәлгә ашыра һәм күрсәтелгән анализ нәтиҗәләре буенча, хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр аналитик белешмә төзи.

7. Аналитик белешмә үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

- кергән, башка кешегә җибәрелгән һәм каралган мөрәҗәгатьләр, шул исәптән, электрон документ формасында кергән мөрәҗәгатьләрне дә кертеп, телдән һәм язмача мөрәҗәгатьләр саны;

- гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында;

- шәхси кабул итүгә килгән гражданнар саны турында;

- гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхси күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында;

- мөрәҗәгатьләрнең темасы турында;

- мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында мәгълүмат (булганда).

8. Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ (аналитик белешмә), шулай ук билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагылышлы иң актуаль мәсьәләләр буенча аңлатмалар Зәй муниципаль районының рәсми сайтында хисап чорыннан соң килүче айның 20 числосына кадәр «Авыл җирлекләре» бүлегенең «Гражданнарны кабул итү» бүлекчәсендә вазыйфаи зат тарафыннан урнаштырыла.